# «Бөркет»

Зөлфия **Фазылбәкова**

(Әнкәй истәлекләреннән)

Бу елны да «Бөркет» кушаматлы киң күкрәкле биек атның Сабан туенда беренчелекне бирмәскә исәбе... Әнә, баскан җирендә ут чыгарырдай итеп таптанып тора. Бигрәк тә шәп күренә! Буй-сыны сокланып туймаслык – елкылдап торган кара-күк төсенә килешеп торган яллары да матур итеп үреп куелган. Кашка – маңгаенда ак йолдызы бар. Дүрт аягы да тездән аста ак төстә. Үз дәрәҗәсен белгәндәй, башын горур, югары тота. Тезгенен дә көмеш тәңкәләр белән бизәгән бит әле хуҗасы. Ел саен тирә-юньдәге сабантуйларының беренче бүләген җыеп кайта алар. Быел да якын-тирәдәге авылларны җиңеп чыктылар. Яраткан хуҗасы Шаһинурның биленә берничә сөлге бәйләнгән.

Бу бүләкләр башка авылларда җиңгән өчен. Ә бүген Гомер агышы... Бөркет үз авылында ашкына. Тизрәк ярышка чыгасы килә аның. Әнә бит, былтыр ярышкан кызыл төстәге яшь айгыр да бик тынгысыз. Тыпырдап торган Алтын яллы бия дә быел бик елгыр-җитез күренә...

Сабан туе мәйданына халык агыла. Иң беренчеләрдән булып малай-шалай йөгерешә. Ялан тәпиле, юеш борынлы малайлар иң яхшы йөгерүчене дә үзара билгелиләр шунда. Бәйрәмгә генә кия торган киемнәрен киенеп-ясанып авыл халкы мәйданга ашыга.

Очына бүләкләр эленгән баганалар утыртылган. Көрәш өчен дә, капчык сугышы өчен дә урыннар хәстәрләнгән. Аркан да үзенең тартышучыларын көтеп ята. Ватар өчен чүлмәкләр әзер. Зур кәкре мөгезле тәкә, ут кикерикле әтәч – бары да үз җиңүчесен көтә. Ә иң кызыклысы – атлар чабышы!

Комиссия әгъзасы Шәйсолтан абзый, кызыл тасма бәйләгән кулын югары күтәреп, кычкырып җибәрде:


– Ат чабышында катнашучыла-а-ар, барыгыз да минем янга-а-а!

Шуны гына көткән Бөркет, башын тагын да югарырак чөйде. Ярыш вакыты якынлашкан саен ярсый бара.

– Без әзер! – дигән кебек, кешнәп тә куйды. Шаһинур ел саен мәйданга беренче килеп җиткәч, билендәге бер сөлгене чишеп, малайлар арасына ыргыта. Ә инде сөлге җиргә килеп төшкәндә, кем иң җитезе, шуңа абзыйсының сабантуй бүләге эләгә. Менә быел да, бер сөлге чишелеп, әзерләп куелды.

Йөрәкләр күкрәктән бәреп чыгардай булып тибә. Шулай булмый, елына бер мизгел генә бит ул – Сабантуй ат чабышлары!

Быелгы ярышта егермеләп ат катнаша. Чабышкылардан Алмачуар күренми, ул яңарак кына колынлаган икән. Аның урынына берничә яшь, өйрәнчек атлар бар. Ярыш юлы да быел бераз озынайтылган. Шәйсолтан абзый елдагыча, барлык кагыйдәләрне аңлатканнан соң, чабышучыларга тезелеп басарга кушты. Юртакларны зур кыенлык белән генә тыеп торалар хәзер.



Менә җәйнең бөркү һавасын Шәйсолтан абзыйның, бу көнне генә ишетелеп калса да, ел әйләнәсенә аланда эленеп торган кабатланмас горур-тәвәккәл тавышы ярып җибәрә:

– Игътиба-а-ар!.. Әзерләнде-е-ек!.. Марш!!!

Бөтенесе бергә кузгалган атлар – кайсы алданрак, кайсы арттанрак төшеп, чабыш юлында үзләренә кулай Гомер агышы... урыннарын ала башладылар. Бөркет уктай алга атыла. Шаһинур абыйсы, Бөркетне тыебрак барса да – алар алдагылар рәтендә. Менә яшь атларның берсе нәрсәдәндер өркеп, ярыш юлыннан читкә тайпылды. Кире кушыла алырмы? Нишлисең, өйрәнчек елларда булгалый инде андый хәлләр... Иң алдан кызыл төстәге яшь айгыр чаба. Гаярь башлады ярышны, әлегә... «Алтын ял» да бер дә калышмый.

Ярты юлны узганнан соң, Шаһинур әкренләп тезгенен бушайтты. Үзе өзәңгедә күтәрелеп, икесе генә аңлаган ишарә ясап, атның муеныннан сыйпап җибәрде:

– Әйдә, Бөркет! Җәй канатларыңны!

Бөркет – «җәйде канатларын»! Янәшәдәге атлар бер-бер артлы артта калалар! Очар йөрәкле җаннар алда! Берсе – Бөркет кушаматлы, ә берсе – Шаһинур исемле! Менә ул, иң дулкынландыргыч мизгелләр!

Менә ул – җиңү тәме! Арттагы тояк тавышлары ерагая бара. Кеше белән ат – икесе бер гәүдә-сынга әверелеп, алга оча!

...Болар – элекке дөньяда калды кебек... Бүген Бөркет колхоз утарында. Ябыккан. Аяклары калтырап тора. Башы аска иелгән. Юк, йокламый – бәхетле елларын күз алдыннан уздыра. Күзләрендә мөлдерәмә яшь...

– Ни булды бу дөньяга? Нигә мине бу тәртипсез кеше кулына бирделәр? Нигә җиргә сеңгән алачыгы тирәли сыңар казык та какмаган, сукбай гомерендә атлар түгел – сыңар кәҗә дә асрамаган, бар дөньяга көнче, усал адәмне хуҗа иттеләр әле миңа? Чын хуҗам – Шаһинурым нигә юк янымда? Мине нигә кыйныйлар? «Кулак калдыгы-ы! Рәхәт яшәгән идеңме? Менә хәзер эшлә дә эшлә», – диеп, ял да иттермичә, юньләп ашатмый да, кыйный-кыйный йөдәтә бу усал адәм...

...Кемдер сарай ишеген ачты. Ат колакларын тырпайтты:

– Шаһинур түгел микән? Ялларымны тарап үрер, борынымнан үбеп, яңакларымнан сыйпар... Тагын да матуррак итеп бизәгән тезгенен кидереп, «Ну, Бөркет, быел да беренчелек безнекеме!?..» – дияр...

– Уяа-ан, кулак калдыгы-ы. На-а. Аяк өсте йоклыйсың, на-а...

Бөркет күзләрен ачып җибәрсә, Шаһинур түгел, ә Сукбай авызлык кидерә. Ял да итмәгән Бөркетне тагын эшкә тарткалый икән. Кинәт Бөркет башын горур күтәрде, фркылдап куйды да арт аякларына күтәрелеп:

– Йе-хо-хо-хо-хоооо! – диеп кешнәп җибәрде. Әйтерсең лә, бөтен кимсетелүләрен күңеленнән чыгарып ташларга теләде. Сукбай тагын камчысына ябышты. Һәрбер сыдырган эз Бөркетнең тәнен утлы күмер баскан кебек яндыра. Җаны – тәненә караганда да ныграк әрни...

– Ярый әле, нәни дустым – Җәннәтем күрми бу хәлләрне. Мине күргән саен елый. Сукбай булмаганда, килеп сыйпап та куя... Үзе өчен алып килгән ипи кисәген каптыра. Бәлки, бүген дә күрешербез әле...

Җәннәт – чын хуҗасы Шаһинурның иң кечкенә, яраткан сеңелкәше. Әнисенә ияреп, колхоз эшенә йөри ул сабый. Атлар сарае кырында, Бөркет чыгасын көтеп тора. Кулында икмәк кисәге. Менә баш бирмәгән атны Сукбай тагын котырып:

– Кулак калдыгы-ы, – дия-дия камчысы белән кыйнарга тотынды. Бөркет нәни дусты каршында сер бирмәскә тырышты. Тик, аяклар тыңламый, калтырыйлар. Күзләреннән тыюсыз яшь ага. Җәннәт түзмәде, йөгереп барып, Сукбайны читкә этәргәндәй итте дә Бөркетне кочаклады. Икесе дә тавышсыз гына елыйлар. Аптырап калган Сукбай да камчысын ташлады... Җәннәт кулындагы ипи кисәкләрен Бөркеткә сузды. Ашарлык рәте дә калмаган малкайның... Бераз яңакларыннан сыйпап торды...

– Сау бул, Бөркетем, иртәгәгә тиклем, – диде дә әнисенә ярдәмгә йөгерде.


Икенче көнне үзе дә ашамаган ипи катысын тотып, Җәннәт юкка гына көтте Бөркетен. Күренмәде ул. Шушы төнне Бөркеткә янә канатлар үсте. Үткән бәхетле елларыннан мәңгегә җиһанда очарга алып киттеләр аны канатлары... Нәни кызчык, кулындагы икмәкне күкрәгенә кысып, күккә карады – биек-биектә зур бөркет әйләнә, гүя, киң канатларын җәеп, кызчыкны иркенлеккә, үз кочагына чакыра...

Җәннәтнең хәтеренә абыйсының Сабантуйларында җиңеп кайткач, чабышны тасвирлап сөйләгәннәре килде... Ул абыйсына охшатып:

– Бөркетем, җәй канатларыңны, җәй канатларыңны! – дип кычкыра-кабатлый, кулларын болгап сәхрага йөгерде...

Аның күңеленә җиңел, рәхәт булып китте – бала йөрәге өзелеп сөйгән дустын бүтән беркем дә, хәтта усал-әшәке Сукбай да рәнҗетә-кыйный алмаячагын аңлап сөенә иде...

P.S. Әнкәем Җәннәт әтисе каяндыр еракտан алып кайткан, колхозлашу чорында таланып алынган үзләренең затлы чабыш атларын, еш кына искә алып, елый-елый сөйләгәндә, парканатлы аргамакның җиргә тияр-тимәс җилеп узганы һәм оча-талпына, бөркеткә әверелеп, һавага ашканы минем күз алдыма килә иде...



/ ФОТОЛАР РЕДАКЦИЯ АРХИВЫННАН.